Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Аксаринского сельского поселения
Заинского муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Аксар авыл җирлегенең
башкарма комитеты

Ул. Ленина, д.42А с. Аксарино,
Заинский район, 423501

Ленин урамы, 42А нче йорт, Аксар
авылы, Зәй районы, 423501

Телефон, факс 3-73-42. Электронный адрес: Aks.zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/aksarinskoe.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№15

КАРАР
09.12.2021г.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160₂ статьясы 4 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлегенең башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар (2022 елга) план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Ю.И.Гильманов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Аксар авыл җирлегенең башкарма комитетының
09.12. 2021 ел
15 номерлы карары
белән расланган.

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Бюджет классификациясе коды | | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы исеме/ Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты керемнәре төре (төрчәсе) кодының исеме |
|---|---|---|
| керемнәрнең баш администраторы | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты керемнәре төре (төрчәсе) | |
| 1 | 2 | 3 |
| 833 | Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы | |
| 833 | 0 10 50201 13 0000 510 | Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты акча средстволарының башка калдыкларын арттыру |
| 833 | 0 10 50201 13 0000 610 | Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты акча средстволарының башка калдыкларын киметү |

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында»
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Башкарма комитеты карар проектына аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Башкарма комитеты карар проекты (алга таба – карар проекты) «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 1 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 17 пунктын гамәлгә ашыру максатларында әзерләнде, аның нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясы 4 пунктның 4 абзацы белән тулыландырылды, ул җирле администрация тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслауны күздә тота.

Карар проекты җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторын җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне исәпкә алып эшләнгән.

Югарыда күрсәтелгән федераль законның 4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләре Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар (2022 елга) план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Карарны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.